КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 758

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын гамәлгә куючыларның функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 2 сентябрь, 758 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны, торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен билгели.

1.2. Урта звено белгечләрен әзерләү программаларын һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар – урта һөнәри белем бирүнең белгечлекләр буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә урта звено белгечләрен әзерләү программаларын һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга кирәкле финанс чараларының рөхсәт ителгән минималь күләме.

1.3.Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларындагы интернатларда һәм тулай торакларда торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар – белем алучыларны билгеләнгән таләпләр нигезендә урнаштыру, карап тоту, аларның туклануын, көнкүрешен һәм буш вакытларын оештыруга кирәкле финанс чараларының рөхсәт ителгән минималь күләме.

1.4. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында белем бирү процессын тәэмин итү өчен бина урыннарын җиһазландыруга карата таләпләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары биналарын эксплуатацияләүнең техник нормалары нигезендә мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) кирәкле финанс чараларының рөхсәт ителгән минималь күләме.

1.5.Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, аларга карата төзәтү коэффициенты, белем алучыларны интернатлардагы һәм тулай торакларндагы торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла һәм ел саен Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

1.6. Урта звено белгечләрен әзерләү программаларын һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар шәһәр һәм авыл җирлеге өчен уку-укыту формасы, һөнәрләр, һөнәри белемнең тиешле дәрәҗәләреннән чыгып, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча дифференциацияләнгән рәвештә елына бер укучыга исәпләп билгеләнә.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, елына бер укучыга исәпләп, төркемдәге белем алучыларның саныннан чыгып билгеләнә:

25 кеше – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында теоретик белем бирү дәресләрендәге төркемнәрдә;

гамәли дәресләр үткәргәндә:

12 – 15 кеше – барлык һөнәрләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары өчен, 8 – 10 кеше – катлаулы җиһазларга хезмәт күрсәтүгә, куркыныч эшләр башкаруга бәйле һөнәрләр буенча, 6 – 10 кеше – «Сәхнә сәнгате һәм әдәби иҗат» һәм «Сәнгатьнең сынлы һәм гамәли төрләре» дигән эреләндерелгән төркемнәрнең белем бирү программаларын тормышка ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары өчен;

10 кеше – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары, түбәндәге махсус (коррекцияле) төркемнәр өчен:

II төр – сөйләме җиңелчә үсеш алмаган, ишетү сәләте бозылган, начар ишетүче һәм соңрак чукракланган балалар өчен;

VI төр – терәк-хәрәкәт аппаратында бозылышлары булган балалар өчен;

VIII төр – акыл үсеше бик нык артта калган балалар өчен;

12 кеше – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары, түбәндәге махсус (коррекцияле) төркемнәр өчен:

IV төр – начар күрүче һәм соңрак сукырайган балалар өчен;

V төр – сөйләмендә авыр бозылышлары булган балалар өчен;

VII төр – психик үсешендә тоткарлыклары булган балалар өчен;

VIII төр – акыл үсеше артта калган балалар өчен;

36 кеше (өч төркемгә берәр социаль педагог һәм тифлопедагог) – сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен.

2.2. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NZ = R_{FOT} + R_{in},$$

монда:

$NZ$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар;

$R_{FOT}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләрнең, административ-идарәчел һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$R_{in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар.

2.3. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләренең, административ-идарәчел һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{FOT} = R_{FOT_{ped}} + R_{FOT_{ayp}},$$

монда:

$R_{FOT}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләренең, административ-идарәчел һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$R_{FOT_{ped}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

$R_{FOT_{ayp}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында административ-идарәчел һәм уку-укыту-ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә торган эш хакын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 май, б-939 нчы боерыгы нигезендә билгеләнә торган урта һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары (башлангыч һөнәри белем бирүче мәгариф оешмаларын кертеп) хезмәткәрләренең гомуми санында административ-идарәчел һәм укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләренең өлешен исәпкә алып исәпләнә.

2.3.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{FOT_{ped}} = \frac{\left(\left(\frac{N_{yno}}{N_{ypr}} \times O_t\right) + \left(\frac{N_{yno}}{N_{pr}} \times O_t\right)\right) \times E \times 12}{P_n},$$

монда:

$R_{FOT_{ped}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында педагог хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$N_{yno}$ – урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә һөнәрләр буенча урта звено белгечләрен әзерләү һәм квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча белем алучының уку йөкләнеше сәгатьләре нормасы;

$N_{ypr}$ – Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагог хезмәткәрләренең эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) һәм хезмәт шартнамәсендә әйтеп үтелә торган педагог хезмәткәрләренең уку йөкләнешен билгеләү тәртибе турында» 2014 елның 22 декабрендәге 1601 нче боерыгы нигезендә билгеләнә торган эш хакы ставкасы өчен уку-укыту (педагогик) эш сәгатьләре нормасы;

$O_t$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә торган эш хакы өчен чыгымнар;

$N_{pr}$ – Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагог хезмәткәрләренең эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) һәм хезмәт шартнамәсендә әйтеп үтелә торган педагог хезмәткәрләренең уку йөкләнешен билгеләү тәртибе турында» 2014 елның 22 декабрендәге 1601 нче боерыгы нигезендә билгеләнә торган эш хакы ставкасы өчен педагогик эше сәгатьләре нормасы;

E – законнар нигезендә иминият кертемнәре күләме;

12 – 1 елда айлар саны;

$P_n$ – белем алучыларның Нигезләмәнең 2.1 нче пункты нигезендә кабул ителә торган норматив саны.

2.4. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{in} = R_{pit} + R_{st} + R_{oop},$$

монда:

$R_{in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар;

$R_{pit}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасы буенча сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар (тәрбияләнүчеләр) һәм урта гомуми белем бирү базасында урта гомуми белем алып белем алучылар өчен туклануны оештыруга «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның туклануын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.4.5.2409-08 нче санитария-эпидемиология таләпләре (алга таба – 2.4.5.2409-08 нче санитария кагыйдәләре һәм таләпләре) белән билгеләнгән чыгымнар;

$R_{st}$ – стипендия белән тәэмин итүгә чыгымнар;

$R_{oop}$ – федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кулланыла торган, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары,

төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, билгеләнгән өлкәдә дәүләт хезмәтләре күрсәтү стандартлары, тәртипләре һәм регламентлары, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән матди, техник һәм хезмәт ресурслары нормаларын, «Башлангыч һөнәри белем бирүче мәгариф учреждениеләрендә уку-укыту-җитештерү процессын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.4.3.1186-03 нче санитария кагыйдәләрен һәм таләпләрен кулланып, Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга чыгымнар (уку әдәбияты, вакытлы басмалар, нәшрият һәм полиграфия хезмәтләре, электрон басмалар, элемтә хезмәтләре сатып алу, шул исәптән җирле, шәһәрара һәм халыкара телефон элемтәсенә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә, транспорт хезмәтләренә чыгымнар һәм башка чыгымнар).

## III. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм тулай торакларда торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

3.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NZ_{in} = FOT_{vos} + R_{pro_{in}} + R_{pit_{in}},$$

монда:

$NZ_{in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$FOT_{vos}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында тәрбиячеләрнең Нигезләмәнең 3.3 нче пункты нигезендә кабул ителә торган хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$R_{pro_{in}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм аны оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.4.2.2821-10 нчы санитария-эпидемиология таләпләре (алга таба – 2.4.2.2821-10 нчы санитария кагыйдәләре һәм таләпләре) белән билгеләнгән агымдагы чыгымнар;

$R_{pit_{in}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүчеләр өчен туклануны оештыруга 2.4.5.2409-08 нче санитария кагыйдәләре һәм таләпләре белән билгеләнгән чыгымнар.

3.2. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы тулай торакларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NZ_{ob} = FOT_{vos} + R_{pro_{ob}},$$

монда:

$NZ_{ob}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы тулай торакларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$FOT_{vos}$ – Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында тәрбиячеләрнең Нигезләмәнең 3.3 нче пункты нигезендә кабул ителә торган хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$R_{pro_{ob}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары каршындагы тулай торакларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә 2.4.2.2821-10 нчы санитария кагыйдәләре һәм таләпләре белән билгеләнгән агымдагы чыгымнар.

3.3. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында тәрбиячеләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FOT_{vos} = (C_{vos} \times O_t) \times E \times 12,$$

монда:

$FOT_{vos}$ – Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында тәрбиячеләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$C_{vos}$ – тәрбияченең тулай торакта яшәүче 100 тәрбияләнүчегә бер ставкасы һәм интернатта яшәүче бер төркемгә бер ставка буларак кабул ителә торган тәрбиячеләр ставкасы саны;

$O_t$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә торган эш хакына чыгымнар;

E – законнар нигезендә иминият кертемнәре күләме;

12 – 1 елда айлар саны.

## IV. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләмен исәпләү тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләме түбәндәгеләрне үз эченә ала:

коммуналь хезмәтләргә чыгымнар;

биналарны һәм корылмаларны агымдагы тотуга (эксплуатацияләүгә) һәм агымдагы ремонтлауга чыгымнар.

4.2. Мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NSI_{uch,ob,in} = K_{uch,ob,in} + F_{uch,ob,in},$$

монда:

$NSI_{uch,ob,in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында уку бинаалары, тулай торак һәм интернат мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләме;

$K_{uch,ob,in}$ – коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме;

$F_{uch,ob,in}$ – биналарны, корылмаларны агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) һәм агымдагы ремонтлауга чыгымнар күләме.

4.3. Уку бинаалары, тулай торак һәм интернатның коммуналь хезмәтләргә чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_{uch,ob,in} = P_{W_{uch,ob,in}} + P_{C_{uch,ob,in}} + P_{G_{uch,ob,in}} + P_{T_{uch,ob,in}} + P_{EL_{uch,ob,in}} + P_{M_{uch,ob,in}},$$

монда:

$K_{uch,ob,in}$ – коммуналь хезмәтләргә чыгымнар зурлыгы;

$P_{W_{uch,ob,in}}$ – су белән тәэмин итүгә чыгымнар зурлыгы;

$P_{C_{uch,ob,in}}$ – су чыгаруга чыгымнар зурлыгы;

$P_{G_{uch,ob,in}}$ – кайнар су белән тәэмин итүгә чыгымнар зурлыгы;

$P_{T_{uch,ob,in}}$ – җылытуга чыгымнар зурлыгы;

$P_{EL_{uch,ob,in}}$ – электр белән тәэмин итүгә чыгымнар зурлыгы;

$P_{M_{uch,ob,in}}$ – каты көнкүреш калдыкларын чыгаруга һәм утильләштерүгә чыгымнар зурлыгы.

4.3.1. Уку бинаалары, тулай торак һәм интернатның су белән тәэмин итүгә, су чыгаруга, кайнар су белән тәэмин итүгә, электр белән тәэмин итүгә, каты көнкүреш калдыкларын чыгаруга һәм утильләштерүгә чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{W,C,G,EL,M_{uch,ob,in}} = N \times T \times (m_1 \times 8 + m_2 \times 4),$$

монда:

$P_{W,C,G,EL,M_{uch,ob,in}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында уку бинаалары, тулай торак һәм интернатның су белән тәэмин итүгә, су чыгаруга, кайнар су белән тәэмин итүгә, электр белән тәэмин итүгә, каты көнкүреш калдыкларын чыгаруга һәм утильләштерүгә чыгымнар зурлыгы;

$N$ – 1 нче таблица нигезендә кабул ителә торган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары;

$T$ – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган тарифлар;

$m_1$ – план елының 1 гыйнварына карата белем алучылар контингенты;

$m_2$ – план елының 1 сентябренә карата белем алучылар контингенты;

8, 4 – 1 елда айлар саны.

4.3.2. Уку бинасын җылытуга чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{T_{uch}} = N \times T \times S \times 12,$$

монда:

$P_{T_{uch}}$ – уку бинасын җылытуга чыгымнар зурлыгы;

$N$ – 1 нче таблица нигезендә кабул ителә торган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары;

$T$ – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган тарифлар;

$S$ – уку бинасының җылытыла торган мәйданы;

12 – 1 елда айлар саны.

4.3.3. Тулай торакны җылытуга чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{T_{ob}} = N \times T \times q \times n \times 12,$$

монда:

$P_{T_{ob}}$ – тулай торакны җылытуга чыгымнар зурлыгы;

$N$ – 1 нче таблица нигезендә кабул ителә торган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары;

$T$ – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган тарифлар;

$q$ – тулай торакта һәм интернатта яшәүчеләр саны;

$n$ – тулай торакта бер яшәүчегә мәйдан беләл норматив тәэмин ителеш 11 кв.метр тәшкил итә;

12 – 1 елда айлар саны.

4.3.4. Интернатны җылытуга чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{T_{in}} = N \times T \times S_{in} \times 12,$$

монда:

$P_{T_{in}}$ – интернатны җылытуга чыгымнар зурлыгы;

$N$ – 1 нче таблица нигезендә кабул ителә торган коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары;

$T$ – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә торган тарифлар;

$S_{in}$ – интернатның җылытыла торган мәйданы;

12 – 1 елда айлар саны.

1 нче таблица. Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары

| Коммуналь хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Уку бинасы | Тулай торак | Интернат |
|---|---|---|---|---|
| Су белән тәэмин итү | куб.метр / кеше, ай | 0,516 | 3,5 | 1,775 |
| Су чыгару | куб.метр / кеше, ай | 0,49 | 3,325 | 1,687 |
| Җылыту | Гкал / кв.метр, ай | 0,017816 | 0,017816 | 0,017816 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | Гкал / кеше, ай | 0,006262 | 0,112399 | 0,042462 |
| Электр белән тәэмин итү | кВт.сәгать / кеше, ай | 57,6 | 26 | 12,5 |
| Каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү | куб.метр / кеше | 0,015 | 0,015 | 0,022 |

4.4. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары биналарын һәм корылмаларын агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) һәм агымдагы ремонтлауга чыгымнар зурлыгы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$F_{uch,ob,in} = C \times S_v \times 12,$$

монда:

$F_{uch,ob,in}$ – биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тотуга (эксплуатацияләүгә) һәм агымдагы ремонтлауга чыгымнар зурлыгы;

$C$ – социаль өлкә учреждениеләре биналарын һәм корылмаларын агымдагы карап тоту һәм ремонтлау буенча билгеләнгән стандартлар нигезендә биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау кыйммәте нормативы;

$S_v$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмасының барлык биналарының җылытыла торган мәйданы;

12 – 1 елда айлар саны.

## V. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибе

5.1. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында финанслар белән тәэмин итү күләме түбәндәгеләрне үз эченә ала:

урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар күләме;

интернатларда һәм тулай торакларда торак урыннар белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар күләме;

мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләме.

5.2. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында финанслар белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$FO = NZ \times \left(\frac{m_1}{12} \times 8 + \frac{m_2}{12} \times 4\right) + (NZ_{ob} \times q) + (NZ_{in} \times q) + NSI_{uch,ob,in},$$

монда:

$FO$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында финанслар белән тәэмин итү күләме;

$NZ$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар;

$m_1$ – план елының 1 гыйнварына карата белем алучылар контингенты;

$m_2$ – план елының 1 сентябренә карата белем алучылар контингенты;

4, 8, 12 – 1 елда айлар саны;

$NZ_{ob}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларындагы тулай торакларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$NZ_{in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларындагы интернатларда торак урыннар белән белем алучыларны тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$q$ – тулай торакта яки интернатта яшәүче укучылар саны;

$NSI_{uch,ob,in}$ – Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларының уку бинасы, тулай торагы һәм интернаты мөлкәтен карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар күләме.

5.3. Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар күләменә төзәтү коэффициенты финанслар белән тәэмин итү күләменең урта звено белгечләрен әзерләү программаларын, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар күләменә карата мөнәсәбәте булып тора.

________________________________